ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

№ 86 18.09.2024

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гомуми тыңлаулар уздыруны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законы нигезендә Аксубай муниципаль районы башлыгы Аксубай муниципаль районы Уставы белән карар чыгарды::

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Яңа Кармәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча Яңа Кармәт авыл җирлегендә яшәүчеләр катнашында гомуми тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Гомуми тыңлауларны оештыручы составын-коллегиаль киңәшмә органын расларга:

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А. М. Мингулов;

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары И. И. Исләмов;

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р. Р. Сарвартдинова;

- Аксубай муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе М. Ә. Габдрахманов;

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы И.Р. Шакиров.

3. Гомуми тыңлауларны оештыручыга гомуми тыңлауларны җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гомуми тыңлаулар үткәрү чорын - кызыксынучы затларга аларны үткәрү турында хәбәр иткән вакыттан алып гомуми тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр билгеләргә.

Гомуми тыңлауларны уздыру срогы бер айдан артмаска тиеш.

5. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитетына иҗтимагый фикер алышулар башлану турында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 маддәсендә каралган хәбәр әзерләргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.rn) һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (https://aksubayevo.tatarstan.ru/).
7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Вакытлыча Аксубай
муниципаль районы башлыгы
вазифаларын башкаручы: И.М. Загидуллин